**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.11.2019 Казан шәһәре № 356

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 7 октябрендә кул куелган 307 номерлы боерыгы белән расланган «Спорт мастерына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, спорт хөкемдарының «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

**боерам:**

1.Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 7 октябрендә кул куелган 307 номерлы боерыгы белән расланган «Спорт мастерына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, спорт хөкемдарының «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне

кертергә:

Регламентның атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, спорт хөкемдарының «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

2.12 пунктында «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына булган таләп атамасы» графасына «дәүләт хезмәте» сүзләреннән соң «, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр» сүзләрен өстәргә;

3.3 пункты 3.3.2 подпунктының дүртенче абзацында «2.8 пунктында» сүзләрен «2.7 пунктында» сүзләре белән алмаштырырга;

3.3 пункты 3.3.2 подпунктының сигезенче абзацында «2.8 пунктында» сүзләрен «2.7 пунктында» сүзләре белән алыштырырга;

4.4 пунктының беренче абзацында «Транспорт һәм логистика идарәсе башлыгы» сүзләрен «Югары казанышлар спортын үстерү бүлеге башлыгы» сүзләре белән алыштырырга;

4.5 пунктында «государстыенной» сүзен «государственной» сузенә алмаштырырга;

5 нче бүлек атамасын түбәнәге редакциядә бәян итәргә:

«5.Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министрның беренче урынбасары Х.Х.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов